РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Нижнеуратьминского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423567, Нижнекамский район,
с. Нижняя Уратьма ул. Центральная, 1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Түбән Уратма авыл жирлеге
Советы

423567, Түбән Кама районы,
Түбән Уратма авылы, Үзәк урамы, 1

тел./факс (8555) 33-17-25, электронный адрес: Nizhneuratminskoe.sp@tatar.ru,
сайт: www.nizhneuratminskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

21.06.2023 ел № 13

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Уратма авыл җирлеге муниципаль мөлкәтенә ия булу, файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2007 елның 13 октябрендәге 21 номерлы Түбән Уратма авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясына ярашлы рәвештә, Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге Советының 2007 елның 13 октябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы муниципаль мөлкәтенә ия булу, файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 бүлекнең 1.3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат такталарында, шулай ук Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

А.Р.Гарифуллин